**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 6 декабрендәге 5054 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 9 июнендәге 3140 номерлы «Казан шәһәренең тарихи территорияләре чикләрен раслау турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2023 елның 11 маендагы 1311 номерлы «Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән “Казан кремле ансамбле” федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектын, XV – XX гасырның беренче чиреге (Татарстан Республикасы (Татарстан) саклау зоналары чикләрен, җирләрдән файдалануның махсус режимнарын һәм әлеге зоналар территорияләре чикләрендәге шәһәр төзелеше регламентларына булган таләпләрне раслау турында»гы әмерен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 20 августындагы 715 номерлы «Казан шәһәренең мәдәни мирас объектларын саклау зоналары, Казан шәһәренең мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зоналары чикләрен, шулай ук җирләрдән файдалану режимнарын һәм әлеге зоналар чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау турында»гы карарын, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 13 мартындагы 218од номерлы «Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә территория, саклау предметы чикләрен һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау турында»гы әмерен исәпкә алып, актуальлеге югалу сәбәпле, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 9 июнендәге 3140 номерлы «Казан шәһәренең тарихи территорияләре чикләрен раслау турында»гы карарын (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 7 августындагы 4653 номерлы, 2015 елның 15 октябрендәге 3732 номерлы, 2017 елның 25 апрелендәге 1442 номерлы карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**